БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__10__» ___04____ 2020 г. № _144____

2020 - 2024 елларга Балтач муниципаль районы халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгытуның муниципаль программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октяберендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 нояберендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, халыкның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру максатларында, «Демография» милли проектының «Иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» региональ проектының төп чараларын үтәү кысаларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә 2020 - 2024 елларга Балтач муниципаль районы халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгытуның Муниципаль программаны расларга.
2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына программа чараларын финанслау өчен акчаларны алдан карап кую.
3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
__2020__ елның __10.04_________
_144____ номерлы карарына
Кушымта

**2020 - 2024 елларга Балтач муниципаль районы халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгытуның муниципаль программасы**

2020 - 2024 елларга Балтач муниципаль районы халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгытуның муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2020 - 2024 елларга Балтач муниципаль районы халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгытуның муниципаль программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Демография» илкүләм проекты |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты |
| Программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты |
| Программаның максаты | Халыкның сәламәтлеген, аларның тормыш сыйфатын яхшырту, иҗтимагый сәламәтлек культурасын, сәламәтлеккә җаваплы караш формалаштыру |
| Программаның бурычлары | - Физик культура белән шөгыльләнүче һәм сәламәт яшәү рәвеше алып баручы халык санын арттыру<br>- Халык тарафыннан тәмәке тартуны, алкоголь куллануны киметү<br>- Халык арасында йогышлы булмаган авырулар белән авыручылар санын һәм үлүчеләр санын киметү |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2020-2024 еллар |
| Программаны башкаручылар | җирле үзидарә органнары, «Балтач РУХ» ДАССУ, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» |

| | |
|---|---|
| | МКУ, мәдәният бүлеге, оешма һәм хезмәт коллективлары җитәкчеләре |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны тормышка ашыру өчен акчаларның гомуми күләме: 730,0 мең сум. |
| Программаның планлаштырылган нәтиҗәләре | Физик культура белән шөгыльләнүче һәм сәламәт яшәү рәвеше алып баручы халык санын 2020 ел башына карата 2% ка артуы, гомуми үлем санының 2019 елга карата 2,8% ка кимүе |

**Программаның максаты һәм бурычлары**

Район гражданнарында сәламәт яшәү рәвешенә, шул исәптән сәламәт туклануга һәм начар гадәтләрдән баш тартуга мотивация формалаштыру.

Сәламәт туклануны (шул исәптән микронутриент җитешсезлекне бетерү, тоз һәм шикәр куллануны кыскарту), тәмәке төтененнән саклауны, алкоголь куллануны киметүне, шулай ук иҗтимагый сәламәтлек программаларын, мәгълүмати-коммуникация кампанияләрен кертүне, гражданнарны иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту чараларына җәлеп итүне дә кертеп, сәламәтлекне ныгытуның корпоратив программаларын эшләү һәм гамәлгә кертү юлы белән сәламәт яшәү рәвеше алып баруга этәрүче мохит булдыру исәбенә сәламәт яшәү рәвеше алып баручы гражданнар санын 2024 елга кадәр арттыруны тәэмин итү.

**Программаны үтәү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре**

| № т/б | Күрсәткеч | Ирешелгән нәтиҗә | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| 1. | Үлүчеләрнең гомуми саны | 10,8 | 10,7 | 10,6 | 10,6 | 10,5 |
| 2. | Халык арасында физик культура белән шөгыльләнүче затларның өлеше, процентларда | 49,5 | 49,8 | 50,0 | 50,2 | 50,5 |

## 5. Программа чараларын гамәлгә ашыру барышы турында хисапның составы, формасы һәм тапшыру вакытлары

Программа чараларын тормышка ашыруның барышы турында хисапның составы, формасы һәм тапшыру вакытлары башкаручы тарафыннан заказчыга Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының норматив-хокукый актларында билгеләнгән таләпләр нигезендә төзелә һәм тапшырыла.

**2020 - 2024 елларга Балтач муниципаль районы халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту буенча муниципаль программасы**

| Т/б № | Чаралар исеме | Үтәү вакыты (еллар) | Финанслау чыганаклары (мең сумнарда) | | | Башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Муниципаль бюджет | Бюджеттан тыш чыганаклар | Барлыгы | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| I. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чараларны оештыру | | | | | | |
| 1.1. | Сәламәт яшәү рәвеше мәсьәләләре буенча федераль һәм республика норматив хокукый актларын һәм методик документларны гамәлгә кертү. | 2020-2024 | - | - | - | Балтач район башкарма комитеты, «Балтач РҮХ» ДАССУ |
| 1.2. | Муниципаль районда алкоголь продукциясен, сыра, тәмәкене чамадан тыш куллануны профилактикалау һәм халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча ведомствоара эшче төркем эшчәнлеген оештыру. | 2020-2024 | - | - | - | Балтач район башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары, «Балтач РҮХ» ДАССУ |
| 1.3 | Гражданнарның сәламәт яшәү рәвешенә, шул исәптән сәламәт туклануга, хәрәкәт активлыгына һәм начар гадәтләрдән баш тартуга юнәлтелгән халыкның төрле максатчан төркемнәре өчен мәгълүмат-коммуникация кампанияләрен оештыру. | 2020-2024 | - | - | - | «Хезмәт» газетасы редакциясе, «Балтач РҮХ» ДАССУ |
| 1.3.1. | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауның | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | көнүзәк мәсьәләләре буенча радио тапшыруларын әзерләү һәм эфирга чыгару. | 2020-2024 | | | | «Кайтаваз» җирле радиосы |
| 1.3.2. | Мәгълүмати таблода, биналар эчендәге ведомство плазмаларында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре буенча социаль реклама трансляциясе. | 2020-2024 | - | - | - | Мәдәният бүлеге, социаль яклау бүлеге җирле үзидарә органнары, «Балтач РҮХ» ДАССУ |
| 1.3.3. | Районда сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре буенча тематик смотр-конкурслар үткәрү (мәсәлән, «Сәламәтлек территориясе», «Тәмәкедән ирекле территория»). | 2020-2024 | 20,0 | 5,0 | 25,0 | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| 1.3.4 | Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы тарафыннан расланган халыкара һәм бөтендөнья даталарын исәпкә алып, массакүләм тематик профилактик акцияләр үткәрү | 2020-2024 | - | - | - | «Балтач РҮХ» ДАССУ |
| 1.3.5. | Проектларга, идеяләргә һәм программаларга, шул исәптән үз-үзеңне тотуның тайпылу фактларына карата шәхси позиция формалаштыруга юнәлдерелгән яшьләр проектларына, идеяләренә һәм программаларына ярдәм итү, рухи һәм физик сәламәтлек принципларында тормыш төзергә омтылуда булышу. | 2020-2024 | 80,0 | - | 80,0 | Җирле үзидарә органнары, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| 1.3.6. | Белем бирү оешмалары, башка оешмалар һәм предприятиеләр арасында сәламәт яшәү рәвеше буенча иң яхшы практикаларга смотр-конкурслар оештыру һәм үткәрү | 2020-2024 | 100,0 | - | 100,0 | «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ |
| 1.3.7. | «Хезмәткә һәм оборонага әзер» | 2020-2024 | - | - | - | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының кышкы Фестивале | | | | | «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ |
| 1.3.8. | «Хезмәткә һәм оборонага әзер» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының җәйге Фестивале | 2020-2024 | - | - | - | «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ |
| 1.3.9. | Районның мәгариф учреждениеләрендә «Дөрес туклану турында сөйләшү» программасын тормышка ашыру | 2020-2024 | - | - | - | «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ |
| 1.3.10. | Гомуми белем бирү оешмалары арасында Бөтенроссия физкультура чараларының муниципаль этапларын, шул исәптән мәктәп укучыларының «Президент ярышлары» Бөтенроссия спорт ярышларын, мәктәп укучыларының «Президент спорт уеннары» Бөтенроссия спорт уеннарын уздыру | 2020-2024 | - | - | - | «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ |
| 1.3.11. | Җәйге туризм буенча район ярышларын уздыру | 2020-2024 | | | | «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ |
| 1.4. | Гаилә белән ял итү һәм гаилә ялы формаларын үстерү, гаиләнең әхлакый-эстетик кыйммәтләрен, мәдәни традицияләрне формалаштыру. | 2020-2024 | - | - | - | җирле үзидарә органнары, ГХАТ бүлеге |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| 1.5. | Балаларның һәрьяклап үсешенә, бала шәхесен җәмгыять мәнфәгатьләрендә гамәлгә ашыруга ярдәм итү. | 2020-2024 | - | - | - | «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| | «Йөзү буенча гомуми укыту» («Всеобуч по | 2020-2024 | - | - | - | «Балтач район башкарма |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | плаванию»)) проектын тормышка ашыру | | | | | комитеты мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| | Эшче һөнәрләр буенча «WorldSkillsBaltasi-Junior» һөнәри юнәлеш бирү буенча ел саен үткәрелә торган чемпионатлар уздыру | 2020-2024 | - | - | - | «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| | «Сәләт» Халыкара яшьләр белем бирү форумында катнашу | 2020-2024 | - | - | - | «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| | «Татарстан табигатен саклыйк!» Республика социаль-экологик конкурсында катнашу | 2020-2024 | - | - | - | «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| | Мәктәп балаларының А.М. Терентьев исемендәге Идел буе фәнни экологик конференциясендә катнашу | 2020-2024 | - | - | - | «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| | Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» Республика конкурсында катнашу | 2020-2024 | - | - | - | «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| | МБГБУ «Нөнәгәр урта гомуми белем бирү мәктәбе» базасында Республика экологик конференциясен уздыру | 2020-2024 | - | - | - | «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| | «Чиста булачак» экологик хәрәкәтенең Республика форумында катнашу | 2020-2024 | - | - | - | «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| II. Иҗтимагый берләшмәләрне җәлеп итеп, хезмәт коллективларында, учреждениеләрдә сәламәт яшәү рәвеше өчен хәрәкәт формалаштыру | | | | | | |
| 2.1. | Хезмәткәрләрнең сәламәтлеген ныгыту буенча, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, шул исәптән тәмәке тартудан, исерткеч эчемлекләрне чамадан тыш кулланудан баш тартуны, сәламәт тукланугa күчү чараларын да кертеп, корпоратив программаларны гамәлгә кертү. | 2020-2024 | 20,0 | 5,0 | 25,0 | Оешма һәм хезмәт коллективлары җитәкчеләре |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| 2.2. | Предприятиеләрдә һәм оешмаларда җитештерү гимнастикасын гамәлгә кертү | 2020-2024 | | | | Оешма һәм хезмәт коллективлары җитәкчеләре |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| 2.3. | Сәламәт яшәү рәвеше мәсьәләләре буенча «Хезмәт» газетасында рубрикалар әзерләү һәм бастырып чыгару. | 2020-2024 | | | | «Хезмәт» газетасы редакциясе, «Балтач РҮХ» ДАССУ |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| III. Алкоголь продукциясен чамадан тыш куллану масштабларын киметү һәм эчкечелекне профилактикалау буенча чаралар | | | | | | |
| 3.1. | Тәртипне, шул исәптән спиртлы продукцияне сатуны чикләү тәртибен, | 2020-2024 | | | | Җирле үзидарә органнары |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | регламентлаучы федераль һәм республика норматив хокукый актларын үтәү буенча контроль-күзәтчелек чаралары. | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| 3.2. | Социаль өлкә, мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау учреждениеләре, бизнес вәкилләре, авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре, иҗтимагый һәм дини конфессияләр белән алкоголь продукциясен чамадан тыш куллануны киметү мәсьәләләре буенча үзара ярдәмләшү һәм хезмәттәшлек итү. | 2020-2024 | | | | Җирле үзидарә органнары, оешма һәм хезмәт коллективлары җитәкчеләре |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| IV. «Гражданнарның сәламәтлеген тирә-юньдәге тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке тарту зыяныннан саклау турында» 2013 елның 23 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү | | | | | | |
| 4.1. | «Гражданнарның сәламәтлеген тирә-юньдәге тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке тарту зыяныннан саклау турында» 2013 елның 23 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыруны оештыру һәм контрольдә тоту буенча чаралар. | 2020-2024 | | | | Җирле үзидарә органнары, оешма һәм хезмәт коллективлары җитәкчеләре |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| 4.2. | Социаль өлкә, мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау учреждениеләре, бизнес вәкилләре, авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре, иҗтимагый һәм дини конфессияләр белән тәмәке тартуның таралуын киметү мәсьәләләре буенча үзара ярдәмләшү һәм хезмәттәшлек итү. | 2020-2024 | | | | Җирле үзидарә органнары, оешма һәм хезмәт коллективлары җитәкчеләре |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| V. Массакүләм физик культураны үстерү чаралары | | | | | | |
| 5.1. | Йорт яны территорияләрен һәм торак пунктларын спорт һәм уен мәйданчыклары, сәламәт яшәү рәвеше буенча мәгълүмати стендлар белән тәэмин итү. | 2020-2024 | 30,0 | 30,0 | 60,0 | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, җирле үзидарә органнары |
| 5.2 | Яшәү урыны буенча төрле яшьтәге халыкның киң катнашында, эшләүчеләр, хезмәткәрләр һәм яшьләр арасында физкультура-савыктыру һәм спорт-массакүләм чаралар (спорт ярышлары, спорт эстафеталары) үткәрү. | 2020-2024 | 400,0 | - | 400,0 | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, җирле үзидарә органнары |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.3. | Яшәү урыны буенча физкультура-спорт юнәлешендәге клуб берләшмәләрен ачу. | 2020-2024 | | | | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, җирле үзидарә органнары |
| 5.4. | Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр арасында спорт эшен оештыру, адаптив физик культура һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру. | 2020-2024 | 40,0 | | 40,0 | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, җирле үзидарә органнары |
| 5.5. | Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү мөмкинлеген тәэмин итү буенча халык өчен социаль чараларны гамәлгә ашыру. | 2020-2024 | | | | Җирле үзидарә органнары |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |